**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СТАРОКУТУШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Ул.Свежухина д.33,с.Старые
Кутуши,423116

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИСКЕ КОТЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Свежухин ур., 33 йорт, Иске Котыш авылы,
423116

тел.(84396)2-72-47
Skut.Cmn@tatar.ru

**№ 7** **07.02.2022ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советын төзү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июнендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советын төзергә.
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы составын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Котыш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.К.Митякин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 7 февралендәге
7 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча координация советы (алга таба - Координация советы) 2007 елның 24 июнендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» РФ Федераль законы нигезендә, җирле үзидарә органнарының, кече һәм урта эшкуарлык субъектлар мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмаларның Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең (алга таба - муниципаль берәмлек) кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү чараларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм үтәүне контрольдә тоту һәм кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә сәясәтне формалаштырганда килештерелгән карарлар эшләү буенча эшчәнлеген координацияләү максатында төзелде.
2. Координация советы кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру буенча киңәшмә органы булып тора.
3. Координация советы
- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне җайга салучы муниципаль берәмлекләрнең муниципаль хокукый актлары проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүдә катнаша;
- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;
- муниципаль әһәмияткә ия булган һәм кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативаларны тәкъдим итә һәм хуплый;
- гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлегенә хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга һәм әлеге мәсьәләләр буенча рекомендацияләр эшләүгә җәлеп итә;
- муниципаль берәмлектә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә комачаулаучы административ киртәләрне бетерү буенча чаралар комплексын эшләүдә катнаша;

- кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү өлкәсендә муниципальара, төбәкара һәм халыкара тәҗрибә алмашуга ярдәм итә.

4. Координация Советы җирле үзидарә органнарыннан, профсоюзлардан, кече эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерцияле булмаган оешмалардан, эшмәкәрләр берләшмәләреннән, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек эшен җайга салучы башка структуралардан муниципаль берәмлекнең кече һәм урта эшкуарлык проблемалары буенча эшләр торышы турында алардан кирәкле материаллар һәм документлар соратып алырга хокуклы.

5. Координация советы утырышына киңәш бирү хокукы белән иҗтимагый оешмалар вәкилләре, шулай ук уку йортлары җитәкчеләре, белгечләр, галимнәр, эшмәкәрләр, экспертлар, консультантлар чакырыла ала.

6. Координация советы комиссияләр төзергә, үз составыннан һәм сөйләшүләрне оештыру, экспертизалар үткәрү, предприятиеләргә күчмә утырышлар үткәрү өчен җәлеп ителгән белгечләрдән эш төркемнәре төзергә мөмкин.

7. Координация советы җәмәгатьчелеккә үз эшчәнлеге турында хәбәр итә. Аның утырышларында массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

8. Координация советы аны булдыру һәм аны раслау турында карар кабул ителгәннән һәм җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан аның турында нигезләмәне раслаганыннан бирле төзелгән дип санала. Координация советының персональ составы авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

9. Координация советы рәисе - авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, рәис урынбасары - авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

10. Координация советы утырышы, әгәр анда аның составының яртысыннан да ким булмаган өлеше һәм тагын бер тавыш булса, тулы хокуклы.

11. Координация советы утырышлары кирәк булган саен, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр уздырыла.

12. Рәис яисә ул булмаганда, - координация советы рәисе урынбасары:

- совет утырышларында мәсьәләләрне карауны әзерләүне оештыралар, рәислек иткән совет утырышлары беркетмәләренә кул куялар;
- советта кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәләр.

13. Координация советы секретаре:

- эшләрне алып баруны, исәпкә алуны һәм саклауны гамәлгә ашыра;
- беркетмә җибәрүне тәэмин итә;
- координация советы эшчәнлеге өчен оештыру-техник чаралар комплексын башкара (катнашучыларны планлаштыру, чакыру, беркетмәләү, исәпкә алу һ.б.).
- совет утырышлары беркетмәләренә кул куя.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 7 февралендәге
7 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы**
**СОСТАВЫ**

Совет рәисе: Митякин А.К.- Иске Котыш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе

Рәис урынбасары: Шохина Е.В.- Баш белгеч-хисапчы

Секретарь: Куркина Т.А.- «Иске Котыш авыл мәдәният йорты» МБУ директоры

Совет әгъзалары: Тепсуркаев В.А.- КФХ
Разин С.Н.-ИП
Хайсанов М.Н.- ИП